**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Балтамак торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

2025 елның 28 ноябре № 2

20.03.2025 елның № 33-ФЗ «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законының 45, 69 нчы маддәләренә туры китереп , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлегенең Балтамак торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Балтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хезмәт итүче, контракт нигезендә хәрби хезмәт итүче, мобилизация буенча хәрби хезмәткә алынган гражданнардан тыш, 2026 елда 10000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)

2) Балтамак торак пунктында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3) Балтамак торак пунктында җирлек территориясен төзекләндерү (аншлагларны ремонтлау, коймаларны буяу, биек агачларны кисү өчен буяулар сатып алу) ;

4) Беларус тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

5) трактор өчен асылмалы җайланма сатып алу;

6) Балтамак торак пунктында су җыю коесы өчен будка сатып алу.

3. Җыен нәтиҗәләрен Рангазар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Кыямов